наб» – перевод непосредственно с оригинала), Гай Сабитов – (переводы «Моабитских тетрадей» Мусы Джалиля, «Шурале», «Туган тел» («Родное слово») и другие произведения Г. Тукая, им же переведены стихотворения *Заки Нури, Роберта Минуллина, Сигбата Хакима, Хасана Туфана и других поэтов-писателей)***,** переводы стихотворений современного удмуртского поэта Ар-Серги на татарский язык и т. д..

Итак, можем утверждать, что взаимодействие двух соседних народов на протяжении длительного времени благотворно влияет на всё историко-культурное развитие обоих народов.

**Литература**

Верещагин, Г. Е. Собр. соч.: в 6 т. /под ред. В.М. Ванюшева. Т. 2: Вотяки Сарапульского уезда Вятской губернии / отв за выпуск Л. С. Христолюбова. – Ижевск: УИИЯЛ УрО РАН, 1996. – 260 с.

Касимов, Р.Н., Пислегин, Н.В. История и особенности исламской культуры в Удмуртии: научно-методическое пособие. – Ижевск: изд-во ИПК и ПРО УР, 2012.– 80 с.

Пислегин, Н. В., Чураков, В.С. Этнокультурное взаимодействие татар и удмуртов в XIX начале XX века // Иднакар: методы историко-культурной реконструкции. 2014. №2 (19). URL: http://cyberleninka.ru/article/n/etnokulturnoe-vzaimodeystvie-tatar-i-udmurtov-v-xix-nachale-xx-veka (Научная библиотека Кибер Ленинка).

Шарафутдинова, А. Г. Персидский пласт словарного состава татарского языка. – Наб.Челны, 1998. – 192 с.

***Юсупов Айрат Фаикович***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНДӘ «*БУЙ*» ТАМЫРЫННАН ЯСАЛГАН БӘЙЛЕК ҺӘМ БӘЙЛЕК СҮЗЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*В данной статье рассматриваются вопросы культуры речи в татарском языке, в частности изучается специфика употребления послелогов и послеложных слов, производных от корня «буй». Выявляются нарушения стилистических норм татарского языка, происходящие вследствие неправильного употребления специфических конструкций родного языка, приводятся правильные варианты данных конструкций.*

**Ключевые слова***: татарский язык; культура речи; послелог; послеложные слова.*

*This article deals with the culture of speech in the Tatar language, in particular, it studies the specifics of the use of postpositions and poslelozhnyh words derived from the root «buoy». Detect violations of stylistic norms of the Tatar language, occurring as a result of misuse of the specific structures of the native language are correct variants of these structures.*

**Key words**: *Tatar language; a culture of speech; postposition; poslelozhnye words.*

Тел чараларының күп үзенчәлекләре сөйләм процессында гына бөтен тулылыгы белән ачыла, алар сөйләм эчендә генә тагын да зур көчкә әвереләләр һәм төрле мәгънә төсмерләре белдерә башлыйлар. Сөйләмне баетып, тулыландырып аңа яңа мәгънә төсмерләре өсти торган тел берәмлекләренә бәйлек һәм бәйлек сүзләр дә керә.

*Буй* тамырыннан ясалган бәйлек сүзләр – үзләре дә бәхәсле һәм каршылыклы фикерләр тудырган тел берәмлекләре. Алар актив телгә әле чагыштырмача күптән түгел генә килеп керделәр, ләкин хәзерге татар әдәби телендә кулланылыш даирәләре арткannan-арта бара. Ф.С. Сафиуллина соңгы елларда әлеге бәйләүче чараларның кулланылыш даирәсен киңәйтүне рус теле йогынтысы нәтиҗәсендә күрә [Сафиуллина, 1990: 41-42]. Хәзерге вакытта *буй* тамырыннан ясалган бәйлек сүзләрнең тел стильләрендә активлашуы, әлеге бәйләүче чараларны аерып алып тикшерүгә нигез булып тора. «*Буенча* бәйлек сүзе, иркенләп, аерым алып тикшерүне таләп итә. Шуны әйтергә кирәк: бу бәйләүче чара башка барлык төрләрне күмеп китәргә омтыла» [Татар грам., 2002: 352].

XX гасырның икенче яртысында басылып чыккан грамматика һәм татар тел белеменә багышланган хезмәтләр нигезендә, *буй* тамырыннан ясалган түбәндәге бәйлек сүзләрне күрсәтергә мөмкин: *буе, буена, буенда, буендагы, буеннан, буенча, буйлап, буйлата, буйлатып, буйлыгы, буйлык* (сөйләмә форма), *буйлый* (сөйләмә форма). *Буе, буена, буенда, буендагы, буеннан, буйлыгы, буйлыгында(гы)* – исемнәрдән; *буйлап, буйлата, буйлатып, буйлый* – фигыль формаларыннан; *буенча* – сыйфат белән рәвештән бәйлек сүзләргә күчә.

*Буенча* бәйлек сүзе урын, вакыт, атрибутив һәм эшнең үтәлү рәвеше мөнәсәбәтләрен белдерә. Әлеге бәйләүче чара җөмләдә процессның һәм горизонталь һәм вертикаль юнәлешен белдерергә мөмкин. *Буенча* бәйлек сүзе вертикаль юнәлешне белдергәндә, җөмләдә еш кына *югарыга, өскә, биеккә, аска, түбәнгә, түбән таба* кебек рәвешләр урын алалар һәм әлеге бәйләүче чара ярдәмендә торган фигыльләр исемнәргә бәйләнә. Мәсәлән: *Хатын барысын да күрә: Гомәр таш стена буенча өскә үрмәләргә тырышып карады да; булдыра алмыйча,кире шуып төште.* (М. Насыйбуллин). *Буенча* бәйлек сүзе горизонталь юнәлештә кулланылганда, горизонталь хәрәкәт мәгънәсенә ия фигыльләрне исемнәргә бәйләүдә катнаша: *Көзге җил усак яфракларын урам буенча бөтерә-бөтерә очыра иде.* (А. Расих). *Буенча* бәйлек сүзе вакыт мөнәсәбәтендә килгәндә, вакыт төшенчәсен белдерә торган сүзләр белән янәшә кулланыла. Мәсәлән: *Җәй буенча кайнар суны бетереп тенкәгә тиделәр.* (Ф. Яруллин).

*Буена* бәйлек сүзе урын (эш-хәрәкәтнең юнәлешен) һәм вакыт (билгеле бер вакыт аралыгында булган эш-хәрәкәтне) мөнәсәбәтләрен белдерә: *Ул кафедрага 1957 елдан алып 1975 елга кадәр, ягъни чирек гасыр буена җитәкчелек итте.* (А.Г. Әхмәдуллин).

*Буе* бәйлек сүзе вакыт мөнәсәбәте (эш-хәрәкәт башкарылу вакытын, аның озынлыгын) белдерә: *Шул ике көндә Ирекнең вакыты булмаса, үзе генә кайтып китә, ике көн буе җен урынына эшли, биатасы белән бианасын таң калдыра.* (Ф. Садриев).

*Буенда, буендагы, буеннан, буйлап, буйлата, буйлатып* бәйлек сүзләре урын мөнәсәбәтен (эш-хәрәкәтнең билгеле бер предмет янында башкарылуын) белдерәләр: *Алар җитәкләшеп, перрон буйлап йөреп килделәр.* (А. Гыйләҗев).

*Буйлыгы, буйлык* бәйлек сүзләре озынлык, биеклек, буйны чагыштырганда кулланыла: *Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.* (Г. Тукай).

Соңгы елларда *буенча* бәйлек сүзенең рус теле тәэсирендә активлашуы, бу бәйләүче чараның татар теленең барлык функциональ стильләрендә дә еш кулланыла башлауына китерде. *Буенча* бәйлек сүзе, бигрәк тә, матур әдәбият, публицистика һәм фәнни стильләрдә зур урын ала. Әлеге хәлгә карата С.М. Ибраһимов болай дип яза: «Соңгы елларда бу бәйлек сүзне куллану чиктән аша башлады. Дөрес, кирәк чагында аларны да алмый мөмкин түгел, әмма андый ешлыкның ярамас ягы да бар... Барысы өчен дә «ярый» торган чара булып, хәзер *буенча* бәйлек сүзе йөри башлады, ул шомарып беткән бакыр биш тиенгә әйләнеп китте» [Ибраһимов, 1976: 103-104].

Проза жанрыннан аермалы буларак, *буенча* бәйлек сүзе поэзиядә гаять сирәк кулланыла. Әлеге бәйләүче чараның тезмә әсәрләр телендә кулланылган очракларда аның *урын* һәм *вакыт* мөнәсәбәтләрен белдереп килүе ешрак күзәтелә. Мәсәлән: *Икебез белгән тугай буенча / Эзләр калды чыкта җемелдәп, / Бетмәс сагыш калды күңелдә.../ Икебезгә уртак моң кайда? – /Тик икебез белгән тугайда!* (Зөлфәт).

Без туплаган мисаллар арасында *буенча* бәйлек сүзе матур әдәбият әсәрләре телендә бер җөмләдә берничә тапкыр килгән очраклар да теркәлгән: *Алдан ук кисәтеп куярга тиешмен: гөлләр, үсемлекләр һәм, әлбәттә, агачлар үстерү буенча белгеч, ягъни, заманча әйткәндә, яшелләндерү буенча инженер – мөһәндис мин.* (А. Хәлим).

Алдагы җөмләдә ике очракта да *буенча* бәйлек сүзе атрибутив мөнәсәбәт белдерә килеп, ияртүче сүзне үзе караган өлкә ягыннан ачыклый. Бер үк бәйләүче чараны бер җөмлә составында ике тапкыр кабатлау стильне бозуга китерә. Мисал итеп китерелгән сүзтезмәләрне түбәндәге рәвешчә төзегәндә, әлеге кимчелекне бетерергә мөмкин:

- иярүче сүз ияртүче исемгә II төр изәфә конструкциясе ярдәмендә сүзтезмә алдагы төзелмәгә синоним рәвешендә карала ала: *үстерү белгече, яшелләндерү инженеры.*

- сүзтезмәләрдә бәйләүче чара итеп *буенча* бәйлек сүзе урынына *өлкәсендә* сүзен кулланып була: *үстерү өлкәсендә белгеч, яшелләндерү өлкәсендә инженер.*

Публицистик стиль, газета-журнал теленә килсәк, *буенча* бәйлек сүзе иҗтимагый-сәяси эчтәлекле язмаларда һәм спорт темасына язылган мәкаләләрдә аеруча күп очрый. Без бу күренешне дә шул ук рус теле белән бәйләп карый алабыз, чөнки күп кенә сәяси төшенчәләрне, сәяси төшенчә белдерә торган сүзтезмә һәм җөмләләр, спорт белән бәйле төшенчәләр турыдан-туры рус теленнән тәрҗемә ителә. Шуңа күрә аерым авторлар рус телендә иң еш кулланыла торган *по* предлогын татар теленә тәрҗемә иткәндә, һәрвакыт *буенча* бәйлек сүзен генә файдаланалар: *Латвиядә автокрос буенча Аурупа чемпионатының IV этап узышлары булды.* («Татарстан яшьләре»).

Вакытлы матбугат битләрендә *буенча* бәйлек сүзенең дөрес һәм урынлы кулланылмаган очракларын да күзәтергә мөмкин. Мәсәлән: *Идел Буе районы эчке эшләр идарәсендә халыкара балаларны яклау көне буенча ятимнәргә ярдәм күрсәтү чарасы гадәткә кереп китте.* («Ватаным Татарстан»). Әлеге мисалда *буенча* бәйлек сүзен *уңаеннан* бәйлек сүзе белән алыштырсак, уңышлырак булыр иде.

*Буенча* бәйлек сүзе фәнни стильдә дә иң еш очрый торган тел берәмлекләреннән берсе булуы ачыкланды: *Аваз төзелеше буенча бер-берсенә охшаш булган, мәгънә ягыннан бөтенләй төрле төшенчәләрне белдергән сүзләр омонимнар була.* (В.Х. Хаков). Гомумән, кайсы гына фән тармагын алып карасак та, *буенча* бәйлек сүзенең гаять күп кулланылуын күрәбез. «Бу бәйлек сүзенең ни дәрәҗәдә урын алуын басылып чыккан китап тышына карап та фикер йөртергә мөмкин: Л. Җәләй. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча очерклар, Ш.А. Рамазанов. Татар теле буенча очерклар, В.Х. Хаков. Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар, Ш.Н. Асылгәрәев. Сәнгатьле уку буенча практикум» [Ибрагимов, 2008: 76].

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: *буенча* бәйлек сүзен урынлы, белеп кулланганда, аның ярдәмендә сөйләмне төрле мәгънә төсмерләренә баетырга, күп мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерергә була. Ә инде җөмлә *буенча* бәйлек сүзе белән чуарланып беткән очракта сөйләмнең аһәңе, яңгырашы бозыла; җөмләдәге сүзтезмәләр генә түгел, ә тулы җөмлә дә аңлаешсыз сүзләр тезмәсенә әйләнергә мөмкин. Шуңа күрә *буенча* бәйлек сүзенең мәгънә төсмерләрен яхшы аңлап, урынлы куллана белү мөһим.

**Әдәбият**

1. Ибраһимов, С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М. Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. – 168 б.
2. Ибраһимов, С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге / С.М. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.
3. Сафиуллина, Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период / Ф.С. Сафиуллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. – 230 с.
4. Татар грамматикасы. 3 томда. Т. II: Морфология. – Казан, Фикер, 2002. – 352 б.

***Юсупов Рузаль Абдуллазянович***

Академия наук Татарстана, Казань

## КОРИФЕЙ ТЮРКОЛОГИИ

*Излагается жизненный и творческий путь одного из крупнейших тюркологов Советского Союза и России, освещаются основные направления его научной деятельности, а также дается характеристика этого выдающегося ученого как высоконравственного человека.*

**Ключевые слова:** *лингвистика, тюркология, древнетюркские памятники, тюркские языки, этнографические материалы, монгольские и уральские языки, диалекты, тюркские наречия, уйгурский язык.*

*The life and career one of the most prominent turkologists of the Soviet Union and Russia, the main areas of his research activities are described in this article.*

**Key words:** *linguistics, turkology, Ancient monuments, Turkic languages, ethnographic materials, Mongolian and Ural languages, dialects, Turkic dialects, Uighur language.*

Эдгем Рахимович Тенишев был уникальным человеком. Эта уникальность – в его широкой масштабности как ученого, большой доброте и отзывчивости как человека, в его высокой интеллигентности.

Э.Р. Тенишев – всемирно известный востоковед-тюрколог, специалист в области сравнительно-исторической грамматики и истории тюркских и монгольских языков, языков древнетюркских памятников и современных тюркских языков. Доктор филологических наук, профессор, заведующий отделом урало-алтайских языков Института языкознания РАН, член-корреспондент АН СССР, академик РАЕН, действительный член Международной академии информатизации, член-корреспондент Турецкого лингвистического общества, Финно-угорского общества, председатель Российского комитета тюркологов, заслуженный деятель науки Татарстана, почетный академик Академии наук Республики Башкортостан.